| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РЫБНО-СЛОБОДСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛЫК БИСТӘСЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.01.2024 Балык Бистәсе штп. № 25пи

“Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру" муниципаль программасын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "2015-2020 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру" дәүләт программасын раслау турында 19.07.2014 № 512 карарына үзгәрешләр кертү хакында» 18.09.2023 ел, № 1150 карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. «Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасын расларга.

2. Үз көчен югалткан дип таныргга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының "2015-2020 елларга Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру" муниципаль программасын раслау турында" 20.01.2015 № 38пи карары;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 20 гыйнварындагы 38пи номерлы карары белән расланган “2015-2020 елларга Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында" 31.05.2016 № 80пи карары;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 20 гыйнварындагы 38пи номерлы карары белән расланган «2015-2020 елларга Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында" 27.09.2016 № 157пи карары;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 20 гыйнварындагы 38пи номерлы карары белән расланган «2015-2020 елларга Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында" 24.09.2018 № 230пи карары;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

Башкарма комитетының 2015 елның 20 гыйнварындагы 38пи номерлы карары белән расланган «2015-2020 елларга Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында"  27.02.2019 № 88пи карары;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 20 гыйнварындагы 38пи номерлы карары белән расланган «2015-2021 елларга Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында"  16.09.2019 № 275пи карары;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 20 гыйнварындагы 38пи номерлы карары белән расланган «2015-2022 елларга Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында"  04.09.2020 № 178пи карары;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 20 гыйнварындагы 38пи номерлы карары белән расланган «2015-2023 елларга Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында "  08.10.2021 № 223пи карары;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 20 гыйнварындагы 38пи номерлы карары белән расланган «2015-2024 елларга Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында "  20.07.2022 № 155пи карары;

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Д.А. Сатдинов

Балык_Бистәсе
муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 29
гыйнварындагы 25 пи
номерлы карары белән
расланган

“Балык Бистәсе муниципаль районының
коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру"
муниципаль программасы

## I. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенең гомуми характеристикасы, проблемалары һәм аларны хәл итү юллары

Коррупция дәүләт һәм җәмгыятьнең социаль-икътисади үсешенә тискәре йогынты ясый, конкурентлыкка сәләтле икътисадны формалаштыруда киртә булып тора, халыкның иминлеген арттыруга, гражданлык җәмгыятенең үсешенә комачаулый.

Шуңа бәйле рәвештә соңгы елларда районда һәм тулаем Татарстан Республикасы буенча коррупциягә каршы тору чараларының активлашуы, республика, ведомство һәм муниципаль дәрәҗәләрдә нормалар төзү һәм хокукны куллану эшен камилләштерү белән характерлана.

Әлеге Программа «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 04.05.2006 ел, № 34-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 9 статьясын, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру «дәүләт программасын раслау хакында "2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында" 18.09.2023 ел, № 1150 карарын үтәү өчен 2015 елгы – 2025 ел, районда коррупциягә каршы тору системасын камилләштерү, коррупцияне профилактикалау, районда коррупциягә комачаулаучы шартлар тудыру максатыннан эшләнгән.

Районның элеккеге коррупциягә каршы программасын үтәү нәтиҗәләре буенча нормалар төзү һәм хокукны куллану буенча зур эш башкарылган. Коррупциягә каршы торуга юнәлдерелгән оештыру, белем бирү һәм тәрбия чаралары күрелә. Әлеге программаларны гамәлгә ашыру вакытында районда коррупциягә каршы тору буенча район башлыгы каршындагы комиссия, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия булдырылган һәм эшли.

Җирле үзидарә органнарында коррупцион хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы затлар билгеләнде һәм эшли, районда коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча башлык ярдәмчесе билгеләнде. Югарыда санап үтелгән коррупцияне профилактикалау субъектларының һәрберсе күзәткән мәсьәләләрнең төгәл даирәсе билгеләнде.

Элекке коррупциягә каршы программалар чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә гражданлык җәмгыяте институтларының коррупциягә каршы эшчәнлектә ролен арттыру билгеләп үтелә. Мәсәлән, җәмәгатьчелек вәкилләре район башлыгы каршындагы коррупциягә каршы тору комиссиясе, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе, район җирле үзидарә органнарының конкурс һәм аттестация комиссияләре составына кертелгән. Массакүләм мәгълүмат чаралары коррупциягә каршы эшчәнлектә актив катнашалар, нәтиҗәдә җәмгыятьтә коррупция күренешләренә карата түземсезлек формалаша.

Районда норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрелә, норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен шартлар тәэмин ителә.

Район халкы фикеренчә, коррупциянең төп сәбәбе-чиновникларның гамәлләренә, аларның керемнәренә һәм чыгымнарына карата җитәрлек дәрәҗәдә катгый контроль булмау, вазифаи затларның бер үзләре генә карар кабул итү мөмкинлеге, халыкның хокукый культурасының түбән дәрәҗәсе.

Коррупциягә каршы тору (профилактика) өлкәсендә югарыда күрсәтелгән проблемаларны хәл итү мөмкинлек бирәчәк:

районда коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру буенча халыкка реаль коррупция хәле һәм күрелә торган чаралар турында мәгълүмат бирү;

коррупциягә каршы тору өчен шартлар тудыру һәм коррупцион хокук бозуларны кисәтү;

җирле үзидарә органнарының гражданлык җәмгыяте белән үзара эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру, коррупциягә каршы тору буенча иҗтимагый берләшмәләрнең эшчәнлегенә дәүләт ярдәме;

коррупциягә каршы торуга юнәлдерелгән булган хокукый, белем бирү һәм тәрбия чараларын эзлекле куллану.

«Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясы нигезендә коррупциягә каршы программа районда коррупциягә каршы торуга юнәлдерелгән хокукый, икътисадый, мәгариф, тәрбия, оештыру һәм башка чараларны килештереп куллануны тәэмин итүче коррупциягә каршы сәясәтнең комплексլы чарасы булып тора.

Районда элеккеге программаларны гамәлгә ашыру тәҗрибәсен исәпкә алып, программа-максатлы ысул районда коррупциягә каршы сәясәт чараларын сыйфатлы гамәлгә ашыру өчен иң максатка ярашлы чара булып тора.

## II. Программаның максаты һәм төп бурычлары. Программаның көтелгән ахыргы нәтиҗәләрен тасвирлау, аны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары

Программаның максатлары булып торалар:

1. Коррупция сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү (коррупцияне профилактикалау), ул җирле үзидарә органнарына 100 процентлы колач бирүне тәэмин итү белән характерлана, аларда коррупциягә каршы оештыру һәм хокукый чаралар, шул исәптән эчке контроль һәм кадрлар сәясәтендә коррупциягә каршы механизм кабул ителгән.

2.Коррупциягә комачаулаучы шартлар тудыру, ул түбәндәге күрсәткечләргә ирешү белән характерлана:

закон чыгару һәм башка норматив хокукый актларның, шулай ук коррупциягә каршы экспертизага дучар ителгән норматив хокукый актлар проектларының өлешен арттыру;

коррупциягә каршы чаралар уздырылган муниципаль хезмәткәрләрнең өлешен арттыру.

3. Җәмгыятьтә коррупциягә карата түземсезлек формалаштыру, ул коррупция ситуациясенә эләккән һәм коррупция килешүенә керүдән баш тарткан гражданнарның өлешен арттыру белән характерлана.

Программаның максатларына ирешү өчен түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү таләп ителә:

“Коррупция сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү (коррупцияне профилактикалау)" максатына ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителә:

коррупциягә каршы тору коралларын һәм механизмнарын, шул исәптән хокукый һәм оештыру механизмнарын камилләштерү;

эшмәкәрлеккә (бизнес-структураларга) административ басымны эзлекле киметү;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының хокук саклау органнары белән хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыру;

көнкүреш коррупциясен киметү буенча чараларны көчәйтү.

«Коррупциягә комачаулаучы шартлар тудыру " максатына ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителә:

коррупциягә каршы экспертиза үткәрү аша норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актлар проектларында коррупцияле факторларны ачыклау һәм бетерү;

коррупциягә каршы укытуны оештыру һәм коррупциягә каршы пропаганданы гамәлгә ашыру, коррупциягә каршы тору өчен гражданлык җәмгыятенең кадрлар, матди, мәгълүмати һәм башка ресурсларын җәлеп итү;

халык өчен ачыклык, җәмәгать хакимияте органнары эшчәнлеген тәэмин итү, аларның гражданлык җәмгыяте белән элемтәләрен ныгыту, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыру;

дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашырганда ачыклык, намуслы конкуренция һәм объективлыкны тәэмин итү.

"Җәмгыятьтә коррупциягә карата түземсезлек формалаштыру" максатына ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителә:

экспертлар берләшмәсен норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына бәйсез коррупциягә каршы экспертиза үткәрүгә җәлеп итү;

гражданнарда коррупциягә тискәре мөнәсәбәт формалаштыру.

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

2024-2026 елларда районның җирле бюджеты акчалары хисабына программаны финанслауның гомуми күләме 168 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

| ел | Районның җирле бюджеты акчалары күләме (мең сум) |
|---|---|
| 2024 | 56 |
| 2025 | 56 |
| 2026 | 56 |

Программаны финанслау күләме фаразлау характерында һәм бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып ел саен коррекцияләнергә тиеш. Моннан тыш, программа чараларын гамәлгә ашыруга чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелгән акчаларны куллану күздә тотыла.

## Муниципаль программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | “Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру" муниципаль программасы |
| Программаның заказчысы | Балык Бистәсе муниципаль районы |
| Программаның төп эшләүче | Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы каршындагы коррупциягә каршы тору комиссиясе |
| Программаның максаты | Коррупция сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү (коррупцияне профилактикалау), коррупциягә комачаулаучы шартлар тудыру, җәмгыятьтә коррупциягә карата түземсезлек формалаштыру |
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары | 2024-2026 еллар |
| Финанслау чыганаклары | Районның җирле бюджеты |

## Муниципаль программаның чаралары (нәтиҗәләре)

| Чараның исеме | Балык Бистәсе МР Башкарма комитетына карамаган башкаручылар (шул исәптән хезмәтләр (килешү буенча) | Чаралар ны үтәү вакыты | Ахыргы нәтиҗә | Муниципаль программаның эш чоры, чараларны финанслау (мең сум) | | | Финанслау чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1. Коррупциягә каршы тору инструментларны һәм механизмнарны, шул исәптән хокукый һәм оештыру механизмнарын камилләштерү, | | | | | | | |
| 1.1. Федераль, республика законнарын үтәүгә һәм Татарстан Республикасында гамәлдәге коррупциягә каршы нормаларны куллану практикасын гомумиләштерү нигезендә коррупциягә каршы тору өлкәсендә район җирле үзидарә органнарының гамәлдәге муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү (кирәк булганда гамәлгә ашырыла) | Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппаратының юридик бүлеге | 2024-2026 еллар | Коррупциягә каршы тору өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуның нәтиҗәлелеген арттыру, әлеге өлкәдә хокукый җитешсезлекләрне һәм каршылыкларны бетерү/ (федераль һәм республика законнарына туры китерелгән коррупциягә каршы тору өлкәсендә җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларының өлеше,%) | - / 100 | - / 100 | - / 100 | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 1.2. Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт | Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре | 2024-2026 | Коррупциягә каршы | - / 100 | - / 100 | - / 100 | Оештыру чарасы, финанслау таләп |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм федераль дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү һәм федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәве турында» 2009 елның 21 сентябрендәге 1065 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәүне тикшерү турында» 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы Указы нигезендә коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча районның җирле үзидарә органнары бүлекчәләренең (коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар хезмәтләренең вазыйфаи затларын) нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү | буенча Башлык ярдәмчесе | еллар | тору эшендә шәхси җаваплылыкны, оешканлыкны һәм профессионализмны арттыру /(коррупциягә каршы торуның кабул ителгән оештыру һәм хокукый чараларының тулылыгы, шул исәптән кадрлар сәясәтендә эчке контроль һәм коррупциягә каршы механизм, %) | | | | ителми |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.3. Муниципаль хезмәткәрләрнең функцияләрен гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган коррупция куркынычларын бәяләү һәм билгән муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә коррупция куркынычларына бәйле рәвештә төгәлләштерүләр кертү (кирәк булганда) | Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе | 2024-2026 еллар | Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коррупцион хокук бозуларны кисәтү максатларында хокукый шартлар тудыру | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 1.4.Туганнары (абыйларының һәм апаларының хатыннары һәм ирләренең абыйлары һәм апалары турында), мәнфәгатьләр конфликты мөмкинлеген ачыклау максатларында муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси эшләрен анализлау һәм хезмәткә кергәндә бирелә торган анкеталардагы мәгълүматларны актуальләштерү | Кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы вазифаи заты | 2024-2026 еллар | Муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы хезмәт тәртибе стандартларын үтәүгә ирешү /(район җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре тарафыннан коррупциягә каршы тору өлкәсендә закон таләпләрен үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән үткәрелгән чараларның өлеше, елына планлаштырылган гомуми саннан %) | - / 100 | - / 100 | - / 100 | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 1.5. Коммерция оешмалары һәм коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның катнашуы мониторингын гамәлгә ашыру | Кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы вазифаи заты | 2024-2026 еллар | Муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы хезмәт тәртибе стандартларын үтәүгә ирешү | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.6. Ведомство карамагындагы оешмалар белән «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясында каралган чараларны, шул исәптән оешмаларның мәнфәгатьләр конфликтын ачыклау, кисәтү һәм җайга салу буенча чараларны күрү бурычын үтәүне тәэмин итү максатларында эшләү | Кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы вазифаи заты | 2024-2026 еллар | Муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы хезмәт тәртибе стандартларын үтәүгә ирешү | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 1.7. Коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясенең еллык эш планнарын раслау һәм үтәү | Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе | 2024-2026 еллар | Коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе эшен тәэмин итү | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 1.8. Муниципаль хезмәт турындагы, коррупциягә каршы тору турындагы закон таләпләрен үтәп, муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, хезмәткәрләрнең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, үз хатыннары (тормыш иптәшләре) һәм балигъ булмаган балаларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерүне үткәрү | Кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы вазифаи заты | 2024-2026 еллар | Муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тулы һәм ышанычлы мәгълүмат бирүгә ирешү | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 1.9. Федераль һәм республика законнары таләпләренә туры китереп муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия эшен тәэмин итү | Кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы вазифаи заты | 2024-2026 еллар | Муниципаль хезмәткәрләрнең чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | таләпләрен үтәвенә ирешү | | | | |
| 1.10. «Юридик затларның бердәм дәүләт реестры» һәм «Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестры» Федераль салым хезмәтенең мәгълүмат базаларын, башка мәгълүмат системаларын (елга бер тапкырдан да ким булмаган күләмдә)кулланып, муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәт турында законнарда каралган чикләүләрне һәм тыюларны үтәүләрен тикшерүне үткәрү | Кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы вазифаи заты | 2024-2026 еллар | Муниципаль хезмәткәрләрнең чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу таләпләрен үтәвенә ирешү | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 2. Коррупциягә каршы экспертиза үткәрү аша норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актлар проектларында коррупцияле факторларны ачыклау һәм бетерү | | | | | | | |
| 2.1. Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен шартлар тәэмин итү һәм күрсәтелгән экспертиза үткәрү нәтиҗәләрен гомумиләштерү | Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппаратының юридик бүлеге | 2024-2026 еллар | Муниципаль норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы мәҗбүри экспертиза үткәрүне гамәлгә ашыру/ (коррупциягә каршы экспертизага дучар ителгән муниципаль норматив хокукый актларның эшләнгән проектлары өлеше,%) | - / 100 | - / 100 | - / 100 | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 3. Коррупциягә каршы укытуны оештыру һәм коррупциягә каршы пропаганданы гамәлгә ашыру, коррупциягә каршы тору өчен гражданлык җәмгыятенең кадрлар, матди, мәгълүмати һәм башка ресурсларын җәлеп итү | | | | | | | |
| 3.1 Вазифа бурычларына | Кадрлар хезмәтенең | 2024- | Муниципаль | - | - | - | Оештыру чарасы, |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| коррупциягә каршы торуда катнашу керә торган, шулай ук муниципаль хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү курсларында коррупциягә каршы тематика буенча дисциплиналарны белем бирү программаларына кертеп, муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрүне тәэмин итү | коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы вазифаи заты | 2026 еллар | хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы хезмәт тәртибе стандартларын үтәүгә ирешү | | | | финанслау таләп ителми |
| 3.2. Муниципаль хезмәткә беренче тапкыр кергән, шул исәптән норматив хокукый актлар белән билгеләнгән вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфаларга керүче муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрүне тәэмин итү | Кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы вазифаи заты | 2024-2026 еллар | Муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы хезмәт тәртибе стандартларын үтәүгә ирешү | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 3.3. Коррупциягә каршы тору өлкәсендә өстәмә һөнәри программалар буенча муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфалары булмаган Вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләр, дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуда катнашкан муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләрен укыту | Кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы вазифаи заты | 2024-2026 еллар | Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашырганда коррупциягә каршы тәртипне саклауга ирешү | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 3.4. Муниципаль хезмәткәрләрдә, муниципаль оешмаларда коррупциягә тискәре мөнәсәбәт | Коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау | 2024-2026 еллар | Муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы | 20 | 20 | 20 | Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| формалаштыру буенча эш, шул исәптән муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан чикләүләрне, тыюларны үтәү буенча оештыру, аңлату һәм башка чаралар күрү, шулай ук коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәү буенча, әлеге эшкә җәмәгать советларын, коррупциягә каршы торуда катнашучы иҗтимагый берләшмәләрне һәм гражданлык җәмгыятьләренең башка институтларын җәлеп итү | буенча эш өчен җаваплы зат | | хезмәт тәртибе стандартларын үтәүгә ирешү, коррупциягә каршы чаралар үткәрелгән хезмәткәрләр өлеше,%) | | | | акчалары хисабына финанслау (мең сум) |
| 4. Татарстан Республикасында җәмәгать хакимияте органнары эшчәнлегенең ачыклыгын, халыкка ачык булуын тәэмин итү, аларның гражданлык җәмгыяте белән бәйләнешен ныгыту, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыру | | | | | | | |
| 4.1. Гражданнарга билгеле булган коррупция фактлары, аларны тормышка ашыруга ярдәм итүче сәбәпләр һәм шартлар турында хәбәр итәргә мөмкинлек бирүче ышаныч телефоннары, кайнар линияләр, башка мәгълүмат каналлары эшләвен тәэмин итү | Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе | 2024-2026 еллар . | Коррупциягә каршы торуда иҗтимагый активлык дәрәҗәсен күтәрү, дәүләт һәм муниципаль органнарның гражданнар белән үзара эшчәнлеген яхшырту / (гражданнарга җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең ачыклыгын, аларга ирешүчәнлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән үткәрелгән чараларның өлеше, гражданлык җәмгыяте белән үзара хезмәттәшлек итү, җәмәгатьчелекнең | - / 100 | - / 100 | - / 100 | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | коррупциягә каршы активлыгын, бер елга планлаштырылган гомуми саннан стимуллаштыру,%) | | | | |
| 4.2. Коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе утырышларында квартал саен гомумиләштереп, аның нәтиҗәләрен карап тикшереп, массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырылган һәм гражданнар һәм юридик затларның мөрәҗәгатьләрендә булган вазифаи затлар эшчәнлегендә коррупция күренешләре турында мәгълүматны мониторинглау | Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе | 2024-2026 еллар | Коррупция дәрәҗәсен киметү | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 4.3. Муниципаль районның рәсми сайтының «Коррупциягә каршы тору» бүлегенең махсус мәгълүмат стендларын рәсмиләштерү һәм актуальләштерү | Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе | 2024-2026 еллар | Муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы хезмәт тәртибе стандартларын үтәүгә ирешү | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 4.4. Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Җәмәгать кабул итү бүлмәсе эшен тәэмин итү | Иҗтимагый совет рәисе | 2024-2026 еллар | Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре өчен шартлар тудыру | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 4.5. Коррупциягә каршы тору эшен координацияләү буенча комиссиянең эшчәнлеген, шул исәптән аның эшчәнлегенә иҗтимагый советлар һәм гражданлык җәмгыятенең башка | Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе | 2024-2026 еллар | Коррупциягә каршы эшчәнлеккә җәмәгатьчелек вәкилләрен җәлеп итү өчен шартлар тудыру | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| институтлары вәкилләрен җәлеп итү юлы белән тәэмин итү | | | | | | | |
| 4.6. Закончар нигезендә муниципаль район сайтында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне урнаштыру | Кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы вазифаи заты | 2024-2026 еллар | Җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең ачыклыгын тәэмин итү, муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәренә, чыгымнарына һәм мөлкәтенә җәмәгать контролен гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 4.7. «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының рәсми сайтлары бүлекләрен урнаштыруга һәм тотыруга Бердәм таләпләрне раслау турында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 4.04.2013 № 225 карарында билгеләнгән таләпләргә яраклы рәвештә муниципаль районның рәсми сайтының "Коррупциягә каршы тору" бүлегенең эчтәлеген тәэмин итү | Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе | 2024-2026 еллар . | Җирле үзидарә органнары эшчәнлегендә ачыклыкны, карарлар кабул итүдә ачыклыкны, урнаштырылган мәгълүматның халык өчен ачык булуын тәэмин итү | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 5. Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашырганда ачыклык, намуслы конкуренция һәм объективлыкны тәэмин итү | | | | | | | |
| 5.1. Муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып | Сатып алулар һәм муниципаль контроль | 2024-2026 | Муниципаль бюджет акчаларын куллануның | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| алуларны тикшерүне гамәлгә ашыру һәм ачыкланган бозуларны бетерү буенча тәкъдимнәр эшләү | идарәсе | еллар | икътисади нәтиҗәлелеген арттыру | | | | ителми |
| 5.2. Конкуренцияне чикләүче шартларны бетерү максатында сатып алына торган товарларның, эшләрнең, хезмәтләрнең характеристикаларын анализлау, шулай ук контрактларның башлангыч максималь бәясен формалаштыруның нигезләнешен үткәрү | Муниципаль районның контроль-хисап палатасы | 2024-2026 еллар | Муниципаль бюджет акчаларын куллануның икътисади нәтиҗәлелеген арттыру | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 6. Эшмәкәрлеккә (бизнес-структураларга) административ басымны эзлекле киметү | | | | | | | |
| 6.1. Эшмәкәрләрнең контроль, күзәтчелек һәм башка дәүләт органнары белән үзара мөнәсәбәтләре мәсьәләләре буенча сораштырулар үткәрү. Хокук бозуларны бетерү буенча карарлар эшләү. | Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге | 2024-2026 еллар | Бизнес структураларына артык административ басымны бетерү (киметү) | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 6.2. Эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының булган административ киртәләр һәм бизнес-структураларга, хокук саклау һәм контроль органнарына тискәре йогынты мәсьәләләре буенча кабул итүләрен оештыру | Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары | 2024-2026 еллар | Бизнес структураларына артык административ басымны бетерү (киметү) | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 7. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының хокук саклау органнары белән хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыру | | | | | | | |
| 7.1. Муниципаль хезмәткәрләрнең законнарда каралган тыюлар һәм чикләүләр буенча муниципаль хезмәт үтү тәртибен үтәүләрен | Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе , | 2024-2026 еллар | Муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы хезмәт тәртибе | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| тикшерү. Тәэмин итү тикшерү нәтиҗәләрен киң таныту | Коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы зат | | стандартларын үтәүгә ирешү | | | | |
| 7.2. Район халкына массакүләм мәгълүмат чаралары аша коррупционерларны фаш итү, вазифаи затларны вазифаларыннан читләштерү, гаеплеләрне җаваплылыкка тарту фактлары турында мәгълүмат җиткерү | Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе | 2024-2026 еллар | Коррупциягә каршы эшчәнлеккә җәмәгатьчелек вәкилләрен җәлеп итү; коррупциягә каршы эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген арттыру | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 7.3. Бюджет акчаларын сарыф иткәндә законнарны шартсыз үтәүгә юнәлдерелгән дәүләт һәм муниципаль контроль органнары белән үзара хезмәттәшлекне оештыру | Муниципаль районның контроль-хисап палатасы | 2024-2026 еллар | Муниципаль бюджет акчаларын куллануның икътисади нәтиҗәлелеген арттыру | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 7.4. Муниципаль хезмәткәрдә мәнфәгатьләр конфликты булу яки барлыкка килү мөмкинлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә яллаучы вәкиленә килгән мәгълүматны тикшерү | Кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы вазифаи заты | 2024-2026 еллар | Муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы хезмәт тәртибе стандартларын үтәүгә ирешү | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 8. Көнкүреш коррупциясен киметү буенча чараларны көчәйтү | | | | | | | |
| 8.1. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның балалар бакчаларына керү чиратын электрон чиратка туры китереп үтәүне тәэмин итү | «Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге»МКУ | 2024-2026 еллар . | Көнкүреш коррупциясе дәрәҗәсен киметү | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 8.2. Агротехник техникум студентлары һәм югары сыйныф | ГАПОУ "Балык Бистәсе Агротехник | 2024-2026 | Көнкүреш коррупциясе дәрәҗәсен киметү | 15 | 15 | 15 | Балык Бистәсе муниципаль |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| укучылары өчен коррупциягә каршы тору тәртибе формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар комплексын эшләү һәм үткәрү | техникумы", «Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге»МКУ | еллар | | | | | районы бюджеты акчалары хисабына финанслау (мең сум) |
| 8.3. Яңа кабул ителгән медицина һәм мәгариф оешмалары хезмәткәрләрен коррупциягә каршы тәртип нормалары белән таныштыру | «Балык Бистәсе РҮХ»ДАССО, «Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге»МКУ | 2024-2026 еллар | Көнкүреш коррупциясе дәрәҗәсен киметү | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 8.4. Россия Федерациясе Торак кодексының нигезләмәләре, торак мөнәсәбәтләрендә катнашучыларның хокуклары һәм бурычлары һәм күп фатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы оешмаларны контрольдә тоту системасы турында басма матбугат басмаларындагы публикацияләр аша халыкка мәгълүмат бирү | Балык Бистәсе муниципаль районында "идарәче компания" ҖЧҖ | 2024-2026 еллар | Халыкның грамоталылыгын арттыру, торак-коммуналь хуҗалык системасында һәм күп фатирлы йортлар белән идарә итү системасында җәмәгать контролен гамәлгә ашыруда шартлар тудыру | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 8.5. Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәмәүнең һәр очрагында законнарда каралган юридик җаваплылык чараларын кулллануны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру | Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе , кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы вазифаи заты | 2024-2026 еллар | Муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы хезмәт тәртибе стандартларын үтәүгә ирешү | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 8.6. Муниципаль хезмәтне алмаштыручы затларның мәнфәгатьләр конфликтын булдырмауга һәм җайга салуга кагылышлы Россия Федерациясе законнарының таләпләрен үтәвен, шул исәптән аларны үтәмәү очрагында андый затларны җаваплылыкка тартуны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру | Кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы вазифаи заты | 2024-2026 еллар | Муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы хезмәт тәртибе стандартларын үтәүгә ирешү | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 9. Экспертлар берләшмәсен норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрүгә җәлеп итү | | | | | | | |
| 9.1. эшләнгән норматив хокукый актлар проектлары һәм аларның җәмәгатьчелек фикер алышу нәтиҗәләрен http://tatarstan.ru/regulation рәсми сайтта урнаштыру | Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппаратының юридик бүлеге | 2024-2026 еллар . | Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү эшен оештыруны камилләштерү, халыкка һәм җәмәгатьчелеккә кабул ителә торган норматив хокукый актлар һәм норматив хокукый актлар проектлары турында мәгълүмат бирү; гражданлык җәмгыяте институтларын муниципаль коррупциягә каршы программаны гамәлгә ашыруга җәлеп итү; җирле үзидарә | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | органнарының хокук иҗат итү эшчәнлегенең сыйфатын арттыру | | | | |
| 10. Гражданнарда коррупциягә тискәре мөнәсәбәт формалаштыру | | | | | | | |
| 10.1. Гражданнарга коррупциягә каршы тору турындагы закон таләпләре турында мәгълүмат бирү һәм җәмгыятьтә коррупциягә карата түземсез мөнәсәбәт булдыруга юнәлдерелгән мәгърифәтчелек чаралары үткәрү | «Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге»МКУ, МКУ "Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни өлкә бүлеге", МКУ "Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге" | 2024-2026 еллар | Коррупциягә каршы эшчәнлеккә җәмәгатьчелек вәкилләрен җәлеп итү; коррупциягә каршы эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген арттыру | 6 | 6 | 6 | Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына финанслау (мең сум) |
| 10.2. Коррупциягә каршы юнәлештәге чараларга мәгълүмати ярдәм күрсәтүне, җәмгыятьтә коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгърифәтчелек эшен тәэмин итү | «Сельские горизонты» («Авыл офыклар") газетасы редакциясе (килешү буенча) | 2024-2026 еллар . | Коррупциягә каршы эшчәнлеккә җәмәгатьчелек вәкилләрен җәлеп итү; коррупциягә каршы эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген арттыру | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |
| 10.3. "Сельские горизонты"("Авыл офыклар") газетасында "Коррупциягә каршы тору өлкәсендә хокукый мәгърифәт" темасына материаллар бастырып чыгару | Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе, «Сельские горизонты» («Авыл офыклар") газетасы | 2024-2026 еллар | Коррупциягә каршы эшчәнлеккә җәмәгатьчелек вәкилләрен җәлеп итү; коррупциягә каршы эшчәнлекнең | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | редакциясе (килешү буенча) | | нәтиҗәлелеген арттыру | | | | |
| 10.4. Мәгариф оешмаларында коррупциягә каршы юнәлештәге конкурслар үткәрү | «Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ | 2024-2026 еллар | Халыкта коррупциягә тискәре мөнәсәбәт формалаштыру | 15 | 15 | 15 | Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына финанслау (мең сум) |
| 10.5. Иҗтимагый совет утырышларында коррупциягә каршы тору программаларын гамәлгә ашыру турындагы хисапны карау | Иҗтимагый совет рәисе, коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе | 2024-2026 еллар | Коррупциягә каршы эшчәнлеккә җәмәгатьчелек вәкилләрен җәлеп итү; коррупциягә каршы эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген арттыру | - | - | - | Оештыру чарасы, финанслау таләп ителми |